КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 23 июнь г.Казань № 743

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Татарстан Республикасы Алабуга һәм Менделеевск муниципаль районнары территориясендә «Алабуга – Гәр – Абалач» – Яңа Менделеевск химия заводы» – Мишкино төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын (Удмуртия Республикасы чигенә кадәр) төзү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегендәге 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасы Алабуга һәм Менделеевск муниципаль районнары территориясендә «Алабуга – Гәр – Абалач» – Яңа Менделеевск химия заводы» – Мишкино төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын (Удмуртия Республикасы чигенә кадәр) төзү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен Татарстан Республикасы, Менделеевск муниципаль районы, «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге адресы буенча урнашкан сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, информатика җирләре, космос эшчәнлеген тәэмин итү җирләре, оборона, куркынычсызлык җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр категориясендәге 3 872 626 кв.метр мәйданлы, 16:27:040401:1393 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән барлыкка килгән 1 309 кв.метр мәйданлы, «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте (алга таба – алына торган җир кишәрлеге милекчесе) милкендәге җир кишәрлеген

(алга таба – алына торган җир кишәрлеге) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Алына торган җир кишәрлегендә урнашкан 16:00:000000:864 кадастр номерлы «Алабуга-500-ПГВ-1 110 кВ һава линиясе» химия һәм нефть химиясе җитештерүләре корылмалары» капиталь төзелеш объекты алынмый дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлеге милекчесенә, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлеге милекчесенә җибәрүне;

килешү төзүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен акча түләүне;

алына торган җир кишәрлегенә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

алына торган җир кишәрлеге милекчесе тарафыннан имза куелган килешү законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъва бирүне.

4. Татарстанның юл-транспорт идарәсенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Алабуга һәм Менделеевск муниципаль районнары территориясендә «Алабуга – Гәр – Абалач» – Яңа Менделеевск химия заводы» – Мишкино төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын (Удмуртия Республикасы чигенә кадәр) төзү» төбәк әһәмиятендәге объектны урнаштыру карала торган территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне межалау проектын раслау турында» 2020 ел, 1 декабрь, 1083 нче карары белән расланган территорияне планлаштыру проекты һәм межалау проекты нигезендә 16:27:040401:1393 кадастр номерлы җир кишәрлегенә һәм алына торган җир кишәрлегенә карата кадастр эшләре үткәрүне тәэмин итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин